# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
# **КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2022 елның 23 сентябрендәге утыз дүртенче утырышына чакырылучылар турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тәкъдим ителмәгән сәяси партияләргә «Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 312-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын карауда катнашырга тәкъдим итәргә, шулай ук әлеге мәсьәлә буенча фикер алышканда ул партия исеменнән чыгыш ясарга вәкаләтле сәяси партия вәкилен билгеләргә.

2. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2022 елның 23 сентябрендәге утыз дүртенче утырышына чакырылучылар составын 175 кеше итеп расларга (кушымта нигезендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 15 сентябре
№ 1552-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2022 елның 15 сентябрендәге
1552-VI ДС номерлы
карарына кушымта

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2022 елның 23 сентябрендәге утыз дүртенче утырышына чакырылучылар составы**

Татарстан Республикасы Президенты

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе

Татарстан Республикасы Премьер-министры

Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе сенаторлары

Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары

Татарстан Республикасы буенча Баш федераль инспектор

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе

Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе

Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе

Татарстан Республикасы Прокуроры

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының җаваплы хезмәткәрләре

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (Премьер-министр урынбасарлары, министрлар, дәүләт комитетлары рәисләре, ведомстволар җитәкчеләре)

Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары җитәкчеләре

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе

Россия Банкының Идел-Нократ баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Милли банк – бүлек идарәчесе

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советлары рәисләре

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе һәм вәкилләре

«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе

Казан шәһәре мэры

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты рәисе

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тәкъдим ителмәгән сәяси партияләр вәкилләре

---

**Барлыгы – 175**